| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>**26.12.2019** | Зеленодольск ш. | **КАРАР**<br>**№ 278** |

2006 елның 1 мартындагы 25 номерлы Зеленодольск Советы карары (2010 елның 24 марттагы 191 номерлы, 2010 елның 30 декабрендәге 25 нче номерлы, 2011 елның 10 июнендәге 15 нче номерлы, 2011 елның 17 нче октябрендәге 65 нче номерлы, 2012 елның 18 маендагы 103 нче номерлы, 2014 елның 21 февралендәге 226 нче номерлы, 2015 елның 8 октябрендәге 12 нче номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр) белән расланган Зеленодольск шәһәре Советы Регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында.

Зеленодольск шәһәре Советы сессияләрен үткәрүне көйләүдә хокукый бушлыкны бетерү максатыннан, Зеленодольск шәһәре Советы **КАРАР ИТӘ:**

1. 2006 елның 1 мартындагы 25 нче номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карары белән расланган Зеленодольск шәһәре Советы Регламентына (2010 елның 24 марттагы 191 номерлы, 2010 елның 30 декабрендәге 25 нче номерлы, 2011 елның 10 июнендәге 15 нче номерлы, 2011 елның 17 нче октябрендәге 65 нче номерлы, 2012 елның 18 маендагы 103 нче номерлы, 2014 елның 21 февралендәге 226 нче номерлы, 2015 елның 8 октябрендәге 12 нче номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 27 матдәнең 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Шәһәр Советының ачык утырышларында гражданнар (физик затлар), дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкилләре, оешмалар (юридик затлар), иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаша ала.»;

1.2. 27 матдәнең 5 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«5. Шәһәр Советының ачык утырышларында катнашучы гражданнар (физик затлар), дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкилләре, оешмалар (юридик затлар), иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре һәм чакырылган затлар шәһәр Советы эшенә тыкшынырга хокуксыз, хуплауларын яисә хупламауларын белдерүдән тыелырга, тәртип сакларга һәм рәислек итүченең күрсәтмәләренә буйсынырга бурычлы»;

1.3. 29 матдәнең 2 пунктындагы 1 бүлекчәсен түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Зеленодольск муниципаль районы Советының һәм шәһәр Советының уртак сессияләрен уздырганда сессияне беренче булып Зеленодольск муниципаль районы Советы рәисе ача, икенчесендә сессияне шәһәр Советы рәисе ача.

Зеленодольск муниципаль районы Советының һәм шәһәр Советының уртак сессияләрен уздырганда сессияне беренчеләрдән булып Зеленодольск муниципаль районы Советы рәисе яба, икенчесендә сессияне шәһәр Советы рәисе яба»;

1.4. 33 матдәнең 1 пунктындагы 1 бүлекчәсен түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Зеленодольск муниципаль районы Советының һәм Зеленодольск шәһәр советының уртак сессияләрен уздырганда, Зеленодольск муниципаль районы Советы рәисе һәм шәһәр Советы рәисе сессияне ачу турында игълан иткәннән соң бер тапкыр дәүләт гимннары башкарыла.

Зеленодольск муниципаль районы Советы һәм Зеленодольск шәһәр советының уртак сессияләрен уздырганда Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт гимннары сессияне ябу турында игълан ителгәннән соң бер тапкыр башкарыла».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында, (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

**Зеленодольск шәһәре мэры урынбасары К.С. Антипов**